СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“19” декабрь 2022 ел** **№ 65**

**«Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү күләме һәм шартлары турында» 2019 елның 15 маендагы 78 номерлы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (22.09.2020 № 7, 27.12.2021 №40 һәм 30.09.2022 № 58 үзгәрешләр белән)**

Муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 12.02.2009 №15-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы түләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.06.2011 №477 карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 13.09.2022 №987 карары, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, урынбасарлары, аудиторлары, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 28.03.2018 ел, № 182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 декабрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы уставы нигезендә Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге органнары хезмәткәрләренең һәм Яңа Кырлай авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәре һәм шартлары турында» 2019 елның 15 маендагы 78 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәте өчен түләү турындагы нигезләмәнең 3 нче абзацын (1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның хезмәт хакы акчалата түләү формасында башкарыла.

| Вазыйфа исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы | 19039 |

2) Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның хезмәте өчен түләү турындагы нигезләмәнең 11 нче абзацын
(1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата бүләкләве елына 9,36 айлык акчалата бүләкләүдән артмаган күләмнәрдә билгеләнә.»

3) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәте өчен түләү турындагы нигезләмәнең 12 нче абзацын (2 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль хезмәтенең биләгән муниципаль вазыйфасына бәйле рәвештә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасы кече төркем белгеченең 12 688 сум күләмендәге вазыйфаи окладына тапкырлау күләмендә билгеләнә.»

4) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәте өчен түләү турындагы нигезләмәнең 33 абзацын (2 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Айлык акчалата бүләкләү хезмәт хакының 18 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органы структурасын үзгәртеп корганда, анда акчалата бүләкләү күләмен исәпләү элек ул биләгән вазыйфа буенча акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итеп башкарылган муниципаль хезмәткәрне элек биләгән вазыйфасыннан түбәнрәк окладлы вазыйфага билгеләү очрагыннан тыш.»

5) Әлеге карарга 3 нче, 6 нчы кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта).

6) Әлеге карарга 7 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегенә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне контрольне үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 19.12.2022 № 65 карарына 3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагыла торган хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында нигезләмә**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге хезмәткәрләренең хезмәт хакы, хезмәткә түләү төренә карап, бер тапкыр тариф коэффициентына нигезләнгән айлык тариф ставкасыннан тора.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче эшчеләргә хезмәт өчен түләү разрядлары диапазоны 5 нче кушымта нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең айлык тариф ставкалары күләме 6 нчы кушымта нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге хезмәткәрләренә түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь зурлык белән чикләнми);

2)еллык түләүле отпуск биргәндә айлык тариф ставкасының 100 % күләмендә матди ярдәм (оклад).

Әгәр хезмәткәргә еллык календарь ел дәвамында түләүле отпуск бирелмәгән булса, түләүле отпуск биргәндә бирелә торган матди ярдәм декабрьдә эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә, эштән киткән очракта - эшнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча исәпләнә һәм түләнә.

Хезмәткәр бероенче ел эшләгәндә еллык түләүле отпуск биргәндә бирелә торган матди ярдәм календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр исәпләнә.

3) билгеләнгән хезмәт хакы фонды чикләрендә матди ярдәм.

Хезмәткәрләргә тиешле федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләр башкарырга.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең айлык һәм башка түләүләре күләме арту ягына бер сумга кадәр түгәрәкләнә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 19.12.2022 № 65 карарына 6 нчы кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ХАКЫ БУЕНЧА ТАРИФ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫ ҺӘМ ТАРИФ СТАВКАЛАРЫ (ОКЛАДЛАРЫ)**

| **Бердәм тариф челтәре түләү разрядлары** | **Тариф коэффициентлары** | **Тариф ставкалары (окладлар), сум** |
|---|---|---|
| 1 | 1,00 | 15 279 |
| 2 | 1,0159 | 15 522 |
| 3 | 1,0323 | 15 773 |
| 4 | 1,0480 | 16 012 |
| 5 | 1,0656 | 16 281 |